# Шәтке мәктәбе тарихы



1916 елларда Шәтке авылы иң караңгы, надан татар авылларының берсе була. Бу вакытта авылда муллалар, остабикәләр үз өйләрендә яки дини мәдрәсәләрдә  дин сабагы биргәннәр.

1916 елның азагында, 1917 елның башларында Габдуллаҗан мулла Шәтке мәдрәсәсендә шәкертләр укыта. Мәдрәсә бинасы Хәкимов Касыймнар йортының каршысында тау башына салынган булган. Кызларны үз йортларында Хөснурый абыстай белән Хәдичә абыстайлар укыта. Шәкертләр укыган өчен муллага һәм абыстайга йә акча, йә икмәк, йә утын китереп бирә торган булганнар. Шуңа күрә авыр тормышлы кешеләрнең балалары укый алмыйча надан калганнар.



Укыту чорында Габдуллаҗан мулла авырый башлый. 1917 елның башында ул үзенең алдынгы шәкертләреннән – Насыйбуллин Госман, Хуҗин Хөсәен һәм Садыйков Сөләйманны һәр классны укыту өчен укытучы итеп билгели. Шәтке авылы мәдрәсәсе 1917 елның февраль революциясен менә шулай каршылый. Бу чорда авылда тоташ укый-яза белмәүчелек (наданлык) була. Кешеләр хат яздырту өчен генә дә Шәтке авылының бер очыннан икенче очына барып, хат язарлык кеше таба алмаганнар. Мәдрәсәдә уку шартлары  бик авыр була. Мәдрәсә кечкенә, кысан, тәбәнәк була. Һава алмаштыру өчен форточкалары булмый. Утырып уку өчен озын, тәбәнәк агач өстәлләр булган. Шәкертләрне аз гына гаепләре өчен дә утын агачлары күиәртеп торганнар, тезләндереп тотканнар, кыйнаганнар. Мәдрәсәдә укучы гшәкертләр бөтенләй белемсез калганнар. Аларга эстетик тәрбия, музыка тәрбиясе бөтенләй бирелмәгән. Малайлар кызлардан аерым укыганнар.

Революциядән соңгы 1918-1923 елларда мәдрәсәдә укытучы итеп Хәсәнов Мәгъсүм билгеләнә. Ул укучыларны яңалыкка таба өйрәтә.

Ул, әле мәктәплӛрдән чыгып бетмәгән дини сабаклар белән бергә яңача өйрәтелә торган дәресләрне дә укыта.



Бу елларда Шәтке авылы кызлары Алан авылыннан килгән укытучы Хәдичә һәм Фатыйма исемле мөгаллимәләрдән белем алалар. Бу мөгаллимәләр дә иске белән яңаны укытуны бергә алып баралар. Боларда укучылардан Кадыйрова Саимә, Янгулова Әминә, Шәрипова Миңлениса, Хәсәнова Маһинурлар һ.б.лар була.

1923-1926 елларда Шәтке мәктәбенә укытучы итеп Янсуар авылыннан Егор абый җибәрелә. Ул Шәтке мәктәбендә яңа программа нигезендә укыта.

1927-1928нче елларда Шәтке мәктәбенә укытучы итеп Сауш авылыннан Сиражетдинов Касыйм җибәрелә. Бу вакытта мәктәп хәзерге колхоз фермасы янында, су буенда урнашкан була.

1923-1933 елларда мәктәптә укытучы булып Бәхтияров Әхмәтвәли, Надыршин Гали, Җәләев Галиләр эшли. Бу елларда укучылар саны күп булу сәбәпле һәм 4 еллык мәҗбүри укытуга күчкәннән соң, иске мәдрәсә бинасы, яңалыкны кертү чоры өчен балаларны укытырга тар була. Шуңа күрә 1934 елның көзендә мәктәп мөдире булып эшләүче Бәхтияров Әхмәтвәли җитәкчелегендә шушы мәктәпнең нигезе корыла. Билгеле бу мәктәпне салу өчен иптәш Бәхтияровка халык белән күп эшләргә туры килә. Ул төрле





каршылыкларга да очрый

1935 елның февраль, март айларында мәктәпнең бурасы бурала. Шул елның апрель аенда авылның барлык яшьләрен җыеп бура

мүккә күтәрелә. Май аенда мәктәп бинасының түбәсе ябыла, түшәм һәа сайгак җәелә. 1935 елның көзендә яңа мәктәптә укытыла башлый. Мәктәп бинасы түбәндәге өлешләрдән тора: 1 зал, 4 класс бүлмәсе, 1 укытучылар бүлмәсе һәм 1 пионер бүлмәсе.

1935 елны Бәхтияров урынына мәктәп мөдире итеп Загрда поселыгыннан Мамаков Александр китертелә.

Яңа мәктәптә уку бәхетенә ирешмәгән Рәхимова Хәмдебикә, Фаттахова Р, Вәлиев Г, Мухаметзянов Г.лар һ.б. шушы мәктәптә башлап укыганнар.

Мамаков Александр 1937 нче елга кадәр Шәтке мәктәбендә укыта, 1937 елны Совет Армиясенә хезмәткә китә. 1937 нче елдан Шәтке мәктәбендә укытучы булып Хәлилова Галимә, Андреев Егор, Гали Җәләев, Гомәр Сабировлар эшлиләр.

1941 нче елны Гали Җәләев, Егор Андреев Бөек Ватан сугышына китәләр, ә Гомәр Сабиров Шәтке авыл Советы рәисе итеп сайлана. Шуы елның көзендә Шәткегә укытучы итеп Мария Елгушова, Гайшә Яруллина, Рая Гыймадиева һәм Миңсылу Зәйнетдиновалар җибәрелә.

1942 елны Гыймадиева белән Зәйнетдинова Шәтке мәктәбеннән китәләр, алар урынына укытучы итеп Анфиса Кутузова килә.

1943-1944 нче елларда Елгушова, Кутузова, Яруллиналар Шәтке мәктәбеннән китәләр, алар урынына укытучы булып Евдокия Федорова, Мария Агапова, Марфа Зимуровалар килә.



1945 нче елны мәктәп мөдире булып Нәдершин Гали кайта.

1946 елны башлангыч класста укытучы итеп Сергей Петров билгеләнә. Шушы елны башлангыч классларга рус телен укыту өчен Димид Тимашов җибәрелә.

1947 елда Д.Тимашов Шәтке мәктәбеннән китә, аның урынына рус телен укытырга Рәшит Хәсәнов килә. Ул Шәтке мәктәбеннән 1948 елда китә, аның урынына Рәисә Шәйхетдинова килә.

1949 елның көзеннән Шәтке башлангыч мәктәбе VII еллык мәктәп итеп үзгәртелә.

Шәтке авылында (1 генә укучы да) 10 классны һәм югары мәктәпне бетерүче кеше, бу елларда һәм алдагы елларда да булмаган.

1950-1951 нче елларда Янсуар урта мәктәбен бетерүче берничә укучы була. Мәсәлән: Галиев Шамил, Хәлилова Роза һ.б.

1949 елны Шәтке мәктәбенә укытучы итеп Пелагия Федорова һәм Максим Оспенниковлар җибәрелә. Бу елны мәктәптә ике 5 нче класс ачыла һәм мәктәпнең 4 классын тәмамлаган барлык укучылар 5 класста укырга тартылалар. Бу елны Гали Нәдершин мәктәп директоры итеп билгеләнә.

Мәктәп җидееллык итеп үзгәртелгән елны бишенче класста түбәндәге укучылар укый: Корбанов Н, Фәйззулина З, Мостафина Ш, Касыймов В, Бәхтияров Фәүзи һәм Вәкил, Димиев Х һ.б.

Мәктәп җидееллык итеп үзгәртелгән елны Шәтке мәктәбенең 1 классына түбәндәге укучылар укырга керә: Батыршина Ф, Зиннәтова Х, Хәлилов Барый, Фәрзиев Н, Якупов М, Габдуллина Р, Сафина Г, Ханов Ә, Кадыйрова З, Галиева С, Гаптриева М, Шәмсетдинова Ф, Маулина Н, Вафин Р, Мәхмүтова Т, Закирҗанова М, Шәмсетдинов М.

1949 елны класслар саны 6 була. Чөнки беренче елны 5 класслар ике була.



1950 елны югары классларга татар теле буенча укытучы итеп Анна Ивачева, башлангыч классларга укытучы итеп Нажия Камалова җибәрелә.

1951 елны 5-7 класслар булдырылу сәбәпле химия-биология буенча укытучы итеп Исхакова Сания, математика-физика буенча Николай Кириллов, Нәгыймә Гассамова, Александр Петров һәм Пелагия Гузяловалар килә. Н.Кириллов һәм А.Петров бер елдан соң Совет Армиясенә хезмәткә алындылар. Башлангыч классларга рус теле укытучысы итеп Анастасия Ильина билшеләнә.



1951 нче елның 16 июненнән Нәдершин Гали гади укытучы булып кала, аның урынына директор итеп шул мәктәпнең  завучы Сергей Петров билгеләнә. Ә Филипп Дадуков шул елның көзендә безнең мәктәпкә завуч итеп җибәрелә.

1951 елда мәктәптә барлыгы 276 укучы була. мәктәптә барлыгы 10 комплект була. Балалар саны күп булганлыктан класс бүлмәләре җитмәде. Шуңа күрә башлангыч класслар 2 сменада, 5-7 класслар 1 сменада укый. Мәктәп бинасы җитмәү сәбәпле шушы елны ике класслы бина төзелә. Бу Газизҗанова Хөснурыйларның бакча башына салына. Соңыннан бина калай түбә белән ябыла һәм рәшәткә белән



тотылып алына. Бу чорда мәктәпкә өлкән пионервожатый бирелә. Безнең мәктәпкә әлеге вазыйфаны башкаручы итеп Гликерия Антонова җибәрелә һәм аңа библиотека эше дә йөкләнелә.

1952 нче елның августеннан Г. Абдуллин укытучы итеп билгеләнә. Ул Шәтке мәктәбеннән соң Янсуар урта мәктәбен тәмамлый һәм үз авылына укытучы булып кайта. Шул елны югары классларга рус теле укытучысы итеп Александра Суворова килә.

1954 елда Шәтке мәктәбенең 7 классын тәмамлап чыгучылардан Хафизова Г, Шәмсетдинова М, Петрова К, Рафикова М, Капитонов А һ.б. була.

1954 елның октябрендә Сания Исхакова гаилә хәле буенча мәктәптән китә.

1955 елның 5 апрелендә укытучы Абдуллин вафат була, аның урынына класс җитәкчесе итеп Гали Нәдершин билгеләнә. 1955 елның августеннан математика укыту өчен Мәгъсүм Хисматуллин җибәрелә.

1955-56 нчы уку елында Шәтке мәктәбенең 7 классын 42 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Вафин Р, Фәрзиев Н, Габдуллина Р, Габдуллин Н, Маулина Н, Шәйхетдинова Ф. һ.б.

1956 нчы елның августеннан мәктәпкә химия-биология укытучысы итеп Хәмит Шакирҗанов җибәрелә. Шул ук елына татар теле укытучысы Гали Нәдершин пенсиягә китү сәбәпле татар теле укытучысы итеп Рушания Хасбиуллина җибәрелә, ул пионервожатый эшен дә алып бара. Бу елларны укучылар саны азайганга күрә өлкән пионервожатыйлык эше укытучыларга өстәмә нагрузка итеп йөкләнде.

Шакирҗанов мәктәп участогында эшне җанландырып җибәрә, фән кушканча эшләп зур уңышка ирешә. Бакчадан шактый суммада керем дә алына.

1956-57 нче уку елын Шәтке мәктәбенең 7 классын 22 укучы тәмамлый.

1957 елны Г.Хасбиуллина китү сәбәпле аның урынына татар теле укытучысы итеп К.Бухарева килде. Шушы елны химия-биология укытучысы Х.Шакирҗанов китү сәбәпле аның урынына Вера Кошкина билгеләнә. Аңа өлкән пионервожатый эше дә йөкләнелә.

1957-58 нче уку елында Шәтке мәктәбенең 7 классын 13 укучы тәмамлый.

1958 нче елның августеннан Шәтке мәктәбенә рус теле укытучысы А.Суворова китү сәбәпле, Петр Александров һәм татар теле укытучысы К.Бухарева китү сәбәпле, Фәридә Александрова җибәрелә.

1958-59 нчы уку елында Шәтке мәктәбенең 7 классын 9 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Гафуров Ш, Салихов И, Тимербаев Х, Фаттахов Н һәм Янгулов С. һ.б.

Мәктәпләрдә укучыларны хезмәткә өйрәтү буенча остаханә кирәк була. Безнең мәктәптә 1960 елның җәендә кирпичтән остаханә салына. Аны төзүдә мастер Г.Нуриев, укуытучылар һәм укучылар актив катнаша. Шушы елның октябренә остаханә җиһазландырыла. 1960 нчы елны Шәтке мәктәбе сигезъеллык итеп үзгәртелә.

1960 нчы елның августенда П.Александров һәм Ф.Александровалар башка мәктәпкә китү сәбәпле, алар урынына рус теле укытырга югары белемле, яңа гына Грузия пединститутын тәмамлаган Рая Латаева, ә татар теле укытытрга Мария Сорокиналар килгән. Шул ук елны хезмәт укытучысы итеп Иван Шуриков билгеләнә.

1960-1961 нче уку елында Шәтке мәктәбенең 8 классын 14 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Бәдриева Б, Габдуллина З, Гыйлманова Н, Давлетшина Ә, Закиров В, Маулин В, Рәхимов Ф һ.б.

1962 нче елның августеннан Рая Латаева һәм МАрия Сорокиналар китү сәбәпле Шәтке мәктәбенә татар теле укытучысы итеп Петров Сергей Кириллович, математика укытучысы итеп Фирдәвес Залялова билгеләнә. Бу укытучылар икесе дә безнең мәктәпнең 7 классын бетереп чыгып, үз мәктәпләренә эшкә кайтучылар.

1961-62 нче уку елында Шәтке мәктәбенең 8 классын 13 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Галиева Р, Габдуллин Г, Газизҗанов М, Гыймадиева К, Нурыева Р, Нургалиева В. һ.б.

1962 нче елның октябрендә хезмәт укытучысы Иван Шуриков башка мәктәпкә китү сәбәпле аның урынына хезмәт укытучысы итеп

Г.Нурыев билгеләнә. Завуч һәм химия-биология укытучысы булып эшләгән Кошкина китү сәбәпле аның урынына Н.Гассамова билгеләнә. Шул елның көзендә рус теле укытучысы булып Сара Ремесленникова килә.

Шәтке мәктәбе әлеге елларда эшләү дәверендә түбәндәге Мактау грамоталары белән бүләкләнә:

- 1957 елның 7 апрелендә "Кошлар көненә карата" стена газетасының яхшы бизәлеше өчен Теләче районы РК ВЛКСМның мактау кәгазе белән;
- 1958 елның 26 мартында "Кошлар көне"н үткәрүдә актив катнашкан өчен (Всесоюзный конкурс) Теләче РК ВЛКСМ һәм Райсоветның Мактау кәгазе белән;
- 1959 елның 16 январенда "Большевик" колхозының кошчылык фермасына шефлык иткәне өчен, пионер дружинасына Татарстан Обком ВЛКСМның Мактау грамотасы белән;
- 1969 елның 25 январенда файдалы хезмәт буенча район ярышында беренче урынны алгын өчен, Теләче РК ВЛКСМ һәм Райсоветның Мактау кәгазе белән;
- 1960 елның 22 маенда район фестивалендә үзешчән сәнгатьтә катнашып 3 урынны алган өчен Саба районыннан Мактау кәгазе бирелә;
- 1962 елның 27 маенда район выставкасында һәм фестивалендә актив катнашкан өчен мактау кәгазе бирелә.

1962-63 нче уку елында Шәтке мәктәбенең 8 классын 19 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Багавиев Г, Вәлиева З, Габдуллин Ф, Галиуллин М, Гафурова Н, Фаттахова Р, Хөсәенова М, Шиһапова Р. һ.б.

1963 нче елның азагында хезмәт укытучысы Г.Нурыев авырып пенсиягә чыга һәм аның урынына 1964 елның башыннан хезмәт укытучысы итеп Барый Хәлимов билгеләнә.

1963-64 нче уку елында Шәтке мәктәбенең 8 классын 29 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Ахметшина Н, Бәдриева Р, Валимухаметова Т, Закирова Г, Закирова Ф, Нәҗметдинова Ж һ.б.

1965 елның апрелендә хезмәт укытучысы Барый хәлилов башка эшкә күчү сәбәпле аның урынына хезмәт укытучысы итеп Ринат Вафин билгеләнә.

1964-65 уку елында Шәтке мәктәбенең 8 классын 18 укучы тәмамлый. Мәсәлән, Гаптриева Х, Галиева Г, Госманов Н, Госманова Н, Ибраев Ф, Мостафина Ә, Нурыева Г, Нургалиева Н, Фаттахов В. һ.б.



1965 елның 7 мартында пенсионер укытучы Гали Надыршин 72 яшендә вафат була.

1965 елның җәендә Шәтке мәктәбе каршында беренче мәртәбә ике сменада пионер лагере оештырыла. Анда 40 пионер ял итә һәм производство күнегүләре уза.

1965 елның август аеннан Шәтке мәктәбенә химия-биология укытучысы итеп Гөлсинә Заляева җибәрелә. 1965-1966 уку елында 8 классны 19 укучы тәмамлый. Әлеге җәйдә ике сменада оештырылган пионер лагеренда 60 пионер ял итә.

1966-67 уку елын – 10, 1967-68 уку елын 23 укучы тәмамлый.

1967 елга Шәтке мәктәбен бетереп чыгучылар арасында – 9 кеше югары белем алган. Шулардан 2 кеше хәрби академия бетерә, 2 кеше агроном, 3 кеше укытучы, 1 кеше врач, 1 кеше юрист белгечлекләре ала. Шул ук вакытта 18 кеше төрле институтларда, берәү хәрби академиядә белем ала.



*1967-68 уку елы* аеруча истәлекле була. Чөнки бөтен Совет халкы Октябрьнең 50 еллыгын билгеләп үтә. *Әлеге елны 8 классны 18 укучы тәмамлый.* 1968 елның августеннан Нырсы мәктәбендә укытучы Заляев Алмас Галиевич физика һәм сызым укытучысы булып Шәтке мәктәбенә күчеп килә. Шушы елда мәктәптә беренче тапкыр Алмас Галиевич җитәкчелегендә хоккей командасы оеша. Аңа “Гром” дип исем бирелә.



*1968-69 уку елында 8 классны 27 укучы тәмамлый.*

1976 нчы елны рус теле укытучысы Шайхутдинова Рәисә Шәкуровна лаеклы ялга китте. Бу уку елында 8 еллык мәктәпне 30 укучы тәмамлады.

1976-77 уку елында рус телен практикант Насретдинова Наилә Зариповна укыта. Уку елын 32 укучы тәмамлый.

1977-78 уку елында рус телен укытырга Фирдәүсә Сафина килә. Мәктәпне 29 укучы тәмамлый.


1978 елда башлангыч класс укытучысы Агачева Маруся лаеклы ялга китә. Физика укытучысы итеп КГПИны бетереп кайткан Заляев Рөстәм Кыямович билгеләнә. Бу уку елында яңа мәктәпкә нигез салына башлый. Мәктәпне 33 укучы тәмамлый.



1979-80 уку елында КПУны бетереп Рәсимә Нурмөхәммәтова һәм Фәния Муллахмәтова башлангыч мәктәпкә укытырга киләләр. 1979 елда Мәгариф отличнигы башлангыч класс укытучысы Пелагия Емельянова лаеклы ялга, рус теле укытучысы Фирдәүсә Сафина гаилә хәле буенча мәктәптән китәләр. 1979 елның июненнән мәктәп директоры булып эшләүче Петров Сергей Порферьевич авыру сәбәпле эштән китә. Сентябрь башында завуч булып эшләгән ***Нәгыймә Гассамова*** аның урынына директор итеп билгеләнә. Ә завуч вазифаларын башкару математика укытучысы Фирдәвес Заляевага йөкләнә. Мәктәпне 34 укучы тәмамлый.



*Яңа мәктәп тарихы*



1980-81 уку елына яңа мәктәп ачыла һәм 1 класска 19 укучы кабул ителә. Завуч булып эшләүче Заляева Фирдәвес гаилә хәле буенча ялга китә. Аның урынына КГПИны кызыл диплом белән тәмамлап кайткан Габдуллина Зөлфирә Котдусовна билгеләнә. Ул шулай ук рус теле фәнен дә укыта башлый. Шушы ук уку елында КПУны тәмамлап Гафурова Мөнирә Габдерүфовна да кайта, ул озайтылган көн группасында эшли башлый.

1981 елдан завуч булып яңадан Фирдәвес Заляева эшли башлый. 1981-82 уку елын тәмамлагач Фәния Муллахмәтова үз теләге белән Казанга күчеп китә. Мәктәпне 25 укучы тәмамлады.

1982-83 уку елы тәмамлангач гаилә хәле буенча Гафурова-Хусайнова мөнирә Габдерүфна Казанга күчеп китә. 1983 елның 29 сентябрендә элекке мәктәп директоры Петров Сергей Порферьевич вафат була. Мәктәпне 21 укучы тәмамлый.

1983-84 нче уку елында Арча педучилищесын бетереп Хусайнова Сәвия Вакыйфовна укытырга кайта. 1984 елның гыйнвареннан Гассамова Нәныймә Гассамовна лаеклы ялга китә. Мәктәпне 16 укучы тәмамлый.



1984-85 уку елы башыннан мәктәп директоры итеп Ибушев Александр Алексеевич билгеләнә. Мәктәпне 20 укучы тәмамлый.

1985-86 нчы уку елында башлангыч класс укытучысы Кадыйров Фәннис Габдуллаҗанович укытырга кайтты. Ибушева Әлфия Габделнуровна татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлады. Татар теле укытучысы Петров Сергей Кириллович хезмәт укытучысы булып күчте. Әлеге елны завуч итеп Рәсимә Фаттахова билгеләнә. Башлангыч класс укытучысы Венедиктова Вера лаеклы ялга китә. Мәктәпнең сигез классын 12 укучы тәмамлый.

1986-87 уку елында Шәтке мәктәбенә урта мәктәп статусы бирелә. Шуңа күрә 22 укучы укуларын 9 класста дәвам итә. 6 укучы СПТУга укырга китә. Математика укытучысы Фирдәвес Заляевага "Укытучы-методист" исеме бирелә.



1987-88 уку елында завуч булып Заляева Фирдәвес Нуриевна эшли башлый. КГПИны бетереп Резеда Габдуллина, Фәридә Хафизова, Миләүшә Ахметшиналар мәктәпкә укытырга кайталар. Иске Җөри мәктәбеннән физ-ра укытучысы Гыйлемҗан Мингалиев та НВП фәне укытырга кайта. 1988 елның



гыйнвареннан Давлетшина Рәзинә Хәкимҗановна озайтылган көн группасына эшләргә килә. 1987 елда мәктәптә районда беренчеләрдән булп компьютер классы ачыла, укучылар информатика фәне укый башлыйлар. Шулай ук әлеге ук елы дәвамында заман таләпләренә туры килерлек яңа

ашханә, китапханә, машина-трактор гаражы, җылыту үзәге төзелә, хезмәт укыту өчен кабинет ачыла.

2000 елда мәктәптә зур спорткомплекс төзелә, 2001 елда киенү-чишенү бүлмәләре белән ике яңа хоккей коробкасы кулланылышка тапшырыла.

